ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 41-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Р. Гайзатуллин, А.Ю. Егоров, А.В. Комисаров, Р.Р. Йосыпов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 41-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 199-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.Р. Гайзатуллин,
А.Ю. Егоров,
А.В. Комисаров,
Р.Р. Йосыпов тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьядагы 14 пунктта «һәм юл буе полосаларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $13^1$ статьядагы $2^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт учреждениеләрендә һәм муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре хезмәт законнары таләпләре нигезендә билгеләнә.»;

3) 26 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Юл буе полосалары, дүртенче һәм бишенче категорияле автомобиль юлларыннан һәм торак пунктлар чикләрендә урнашкан автомобиль юлларыннан тыш, автомобиль юлларының барлык категорияләре өчен билгеләнә.»;

б) 7 өлештә «автомобиль юлы хуҗасының язма ризалыгы» сүзләрен «автомобиль юлы хуҗасы белән язма килештерү» сүзләренә, «ризалыкта» сүзен «килештерүдә» сүзенә алмаштырырга;

в) $7^1$ өлештә «килешүсез» сүзен «килештерүсез» сүзенә алмаштырырга;

г) $7^2$ өлештә «ризалыкта» сүзен «килештерүдә» сүзенә, «төзүгә, реконструкцияләүгә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә ризалык алу» сүзләрен «төзүне, реконструкцияләүне әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә килештерү» сүзләренә алмаштырырга;

д) $7^3$ өлештә «төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык бирү» сүзләрен «төзүне, реконструкцияләүне килештерү» сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешнең үз көчен югалтуын тану хакында» 2024 елның 26 декабрендәге 485-ФЗ номерлы Федераль закон белән дүртенче һәм бишенче категориядәге юлларга карата автомобиль юлларының юл буе полосаларын билгеләү зарурлыгы турындагы таләпләр төшереп калдырылды.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрен билгеләү тәртибе төгәлләштерелде, аның нигезендә мондый таләпләр хезмәт законнары нигезендә билгеләнәчәк (элек Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә иде).

Закон проекты белән «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына шундый ук үзгәрешләр кертү каралган.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү түбәндәгеләрне таләп итәчәк:

1) «Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары турында» 2008 елның 1 декабрендәге 841 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү;

2) «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм Татарстан Республикасында юл хуҗалыгында региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләте бирелгән дәүләт учреждениеләрендә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрен раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 610 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының үз көчен югалтуын тану.

**«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.